Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл жирлеге Оргыды авылы
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«15» ноктябрь, 2025 ел № 2

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештырунын гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Сәмәкәй авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл жирлегенең 01.11.2019 ел «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Сәмәкәй авыл жирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар жыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында «42/2 номерлы»нигезләмәне раслау хакында", нигезендә Оргыды авылы гражданнар жыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2026 елда яшәү урыны буенча "Сәмәкәй авыл жирлегенен Оргыды авылы территориясендә 2026 елда балигъ булган, Сәмәкәй авыл жирлегенен Оргыды авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йоз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Сәмәкәй авыл жирлеге территориясендә теркәлгән гражданнарны һәм гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-торак пункт чикләрендә жирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокыр ремонтлау, юллар төзү, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре).

2. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл жирлеге Оргыды авылы гражданнар жыены нәтиҗәсен авыл жирлегенен мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка житкерергә.

3. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл жирлеге Оргыды авылы гражданнар жыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл жирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,
Оргыды авыл жирлеге Башлыгы И.М.Усманов